СОВЕТ БИШНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 29 апреле** Бишнә ав. **№224**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт хакы күләмен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 28.09.2020 №7 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Советның 26.09.2022 №97, 29.12.2022 №117, 03.06.2024 №186, 05.12.2024 №206 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәтенә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 28.09.2020 елның 7 номерлы карарына (Советның 26.09.2022 № 97, 29.12.2022 №117, 03.06.2024 №186, 05.12.2024 №206 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1). 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2) икенче абзацта «19173 (унтугыз мең йөз житмеш өч сум күләмендә һәм 20548 (егерме мең биш йөз кырык сигез) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «21091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 27208 (егерме җиде мең ике йөз сигез) сум күләмендә» сүзләре белән алмаштырырга;

2). 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «19173 (унтугыз мең йөз җитмеш өч сум күләмендә» сүзләрен «21091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга»;

3) 3 пунктта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бишнә авыл җирлеге Советының 2025 елнын 29 апрелендәге №224 карарына Кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КУЛЭМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының атамалары** | **Айлык күләме вазифа хезмәт хакы, сум** |
|---|---|
| Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) | 20468 |
| Әйдәп баручы белгеч | 17082 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**